„ПВХО га ХӘЗЕР“ НОРМАЛАРЫНЫҢ

БЕРЕНЧЕ БАСКЫЧЫ

ТАТГОСИЗДАТ
КАЗАН 1941

СССР Осоавиахимы Үзәк Советының ПВХО идарәсе

„ПВХО ГА ХӘЗЕР“ НОРМАЛАРЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ БАСКЫЧЫ

ТАТГОСИЗДАТ
КАЗАН 1941

„Раслыйм"
СССР Осоавиахимының Үзәк Советы
председателе
авиация генерал-майоры
П. Кобелев
1941 нче елның 18 нче апреле.

„ПВХО ГА ХӘЗЕР" НОРМАЛАРЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ БАСКЫЧЫ

БЕРЕНЧЕ НОРМА

Фугаслы һәм осколкалы бомбалардан саклану

Яшеренү урыны итеп подвалларның ничек файдаланылуын һәм убежищеларда һәм кыр тибындагы яшеренү урыннарында үзеңне ничек тотарга икәнен белергә.

Түбәндәгеләрне эшли белергә: 1) яшеренү өчен тирән тар чокырлар (щели) казу һәм алардан файдалана белергә; 2) зарарланган кешеләрне коткару өчен, ишелгән урыннарны актарып ача белергә; 3) кан агуын туктата белергә һәм кул астында булган әйберләр белән һәм индивидуаль пакет белән яраны бәйли белергә; 4) зарарланган кешеләрне кулга күтәреп яки кул астында булган әйберләр ярдәме белән бер урыннан икенче урынга күчерә белергә 5) кешенең тәне өшегән яки яктырту газлары белән һәм углерод оксиды белән агуланган хәлләрдә врачка кадәр ярдәм күрсәтә белергә.

ИКЕНЧЕ НОРМА

Яндыргыч средстволардан саклану

Үз өеңдә пожар чыгу куркынычын ничек итеп киметергә һәм яндыргыч бомбаларны сүндерү өчен нинди средстволар хәзерләргә кирәк икәнен белергә.

Түбәндәгеләрне эшли белергә:

1) яндыргыч средстволарның җәелеп китүләрен ком һәм су ярдәме белән туктата һәм аларны биналардан тышка чыгарып ташлый белергә; 2) пожарны күбекле сүндергечләр һәм биналар эчендәге пожар краннары белән сүндерә белергә; 3) яна торган кешенең

өстендәге киемнәрен сүндерә һәм яна торган сыек нәрсәләрне сүндерә белергә; 4) пешкән кешеләргә врачка күренгәнче ярдәм күрсәтә белергә.

ӨЧЕНЧЕ НОРМА

Агулаучы матдәләрдән саклану

Түбәндәгелерне белергә:

1) һаваның, урыннарның һәм төрле әйберләрнең тышкы күренешләреннән, аларда агулаучы матдәләр (ОВ) барлыгын белергә; 2) үзеңә яраклы үлчәүдә маска, шлем сайлап ала һәм противогазны җыя белергә; 3) противогазны дөрес кия, сала, бөкләп җыештыра һәм сумкага салып куя белергә; 4) противогазның төзек булмаган урынын таба белергә, төзек булмаган противогаздан файдалана һәм аны төзек булган противогаз белән алмаштыра белергә; 5) зарарланган кешегә противогаз кигезә белергә; 6) противогаз киеп, кимендә бер сәгать торырга; 7) ОВ белән агуландырылган районда торганда һәм агуландырылган участканы аша үткәндә үз-үзеңне саклау чараларын һәм саклану өчен кул астында булган средстволарны куллана белергә; 8) ашамлыкларны, суны һәм өй кирәк-ярак әйберләрен агуланудан саклый белергә; 9) химия һөҗүменә каршы булган пакеттан файдалана белергә.

ДҮРТЕНЧЕ НОРМА

Һава һөҗүменә каршы оборона (ПВО) шартларында халыкның үз-үзен тотудагы бурычлары һәм аның кагыйдәләре

Түбәндәгеләрне белергә: 1) торак өйләрдә (эшләүче кешеләр өчен — предприятие һәм учреждениедә, укучылар өчен — уку йортларында) ничек итеп ПВО оештырырга кирәклеген; 2) куркынычлы хәлне кем һәм ничек игълан итә икәнен һәм куркынычлы хәл вакытында үз өеңдә нәрсә эшләргә кирәклеген белергә; 3) „Һава тревогасы“, „Химия тревогасы“, „Һава тревогасыннан отбой“ булганда һәм пожар вакытында урамда, эштә, җәмәгать тупланышы урыннарында һәм өйдә үз-үзеңне ничек тотарга кирәклеген белергә; 4) зарарлар һәм зарарланучылар турында ничек һәм кемгә хәбәр итәргә икәнен белергә.

Үз өеңдә яктылыкны яшерә белергә.

УКУ ВАКЫТЫНЫҢ ХИСАБЫ

Темаларның номеры	Темаларның исемнәре	Сәгать саны
1	Хәзерге заман сугышында тылны һава һәм химия һөҗүменә каршы хәзерләүнең әһәмияте һәм Осоавиахимның бурычлары	2
	Беренче норма — „фугаслы һәм осколкалы бомбалардан саклану“	
2	Фугаслы һәм осколкалы авиабомбаларның җимерү эше һәм алардан саклану	4
3	Фугаслы һәм осколкалы бомбалар белән бомбардировкадан зарарланган кешеләргә беренче ярдәм . . .	3
	Икенче норма—„яндыргыч средстволардан саклану“	
4	Яндыргыч средстволарның яндыру эше	1
5	Үз өеңдә пожар чыгу куркынычын ничек итеп киметергә	1
6	Яндыргыч средстволарны һәм алардан кабынган пожарны сүндерү	4
	Өченче норма — „агулаучы матдәләрдән саклану“	
7	Агулаучы матдәләр һәм аларны таный белү ысуллары	2
8	Агулаучы матдәләрдән (ОВ дан) саклану чаралары .	5
9	ОВ белән агулануның билгеләре һәм агуланган кешеләргә врачка күренүгә кадәр ярдәм күрсәтү	2
	Дүртенче норма — „һава һөҗүменә каршы оборона (ПВО) шартларында халыкның үз-үзен тотудагы бурычлары һәм аның кагыйдәләре“	
10	Торак йортларда ПВО оештыру	2
11	ПВО шартларында халыкның үз-үзен тотудагы бурычлары	2
	Барлыгы . . .	28 сәгать

„ПВХО ГА ХӘЗЕР“ НОРМАЛАРЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ БАСКЫЧЫ БУЕНЧА ЗАНЯТИЕЛӘР ПРОГРАММАСЫ

КЕРЕШ ЗАНЯТИЕ

1 нче тема. Хәзерге заман сугышында тылны һава һәм химия һөҗүменә каршы хәзерләүнең әһәмияте һәм Осоавиахимның бурычлары (2 сәгать)

Занятиенең максаты. Тылда ПВО ның бурычлары белән һәм Осоавиахим оешмаларының халыкны ПВО га хәзерләү бурычлары белән таныштыру.

Теманың эчтәлеге. Сугышучы илләрнең армиясенә, промышленностена, транспортына һәм халкына зарар китерүдә авиациянең роле. Шәһәрләргә ясалган налет вакытларында авиациянең эшләре. Тылга зарар итүдә авиация тарафыннан кулланыла торган средстволар. Тылда ПВО ның әһәмияте һәм бурычлары. АЗО, ВНОС һәм МПВО ның әһәмияте һәм средстволары турында төшенчә. Халыкны ПВХО га хәзерләүдә Осоавиахимның бурычлары.

Занятие уздыруның методлары. Хәзерге заман самолетларының һәм АЗО, ВНОС һәм МПВО средстволарының максатларын, чертежларын һәм рәсемнәрен күрсәтү юлы белән беседа алып бару.

БЕРЕНЧЕ НОРМА БУЕНЧА

2 нче тема. Фугаслы һәм осколкалы авиабомбаларның җимерү эше һәм алардан саклану (4 сәгать)

Занятиенең максаты. Фугаслы һәм осколкалы авиабомбаларның җимерү эше белән таныштыру һәм дошман тарафыннан фугаслы һәм осколкалы бомбалар кулланган вакытта халыкны алардан ничек дөрес сакланырга өйрәтү.

Теманың эчтәлеге. Фугаслы һәм осколкалы авиабомбаларның ни өчен кулланылуы; аларның төзелешләре һәм зарарлары турында аңлату. Халыкның фугаслы һәм осколкалы авиабомбалар зарарыннан саклану чаралары: авиабомбалардан саклану өчен махсус убежищелар, аларның ни өчен кирәк булулары һәм алардан файдалану, подвалларны бомбалардан саклану өчен файдалану һәм подваллардан файдалану ысуллары. Ачык калдырып һәм томалап ясалган тар чокырлар (щели) һәм аларның ни өчен кирәк булулары. Саклану чокырларын казу өчен тиешле урыннар сайлау. Сайланган урынны билгеләү, чокырның юнәлешләрен билгеләү, казу һәм чокырларны җиһазландыру, алардан файдалану ысуллары. ВТ (һава тревогасы) сигналлары буенча халыкның фугаслы бомбалар зарарыннан качыну тәртипләре. Шартламаган бомбалар булганда халыкның үз-үзен тотуы.

Занятие уздыруның методы. Тема ике занятиегә бүленә: беренче занятие — „Фугаслы һәм осколкалы бомбаларның ни өчен хезмәт итүләре, аларның төзелешләре һәм җимерү эшләре турында аңлату“ (1 сәгать) һәм икенче занятие — „Фугаслы һәм осколкалы бомбаларның зарарларыннан саклану“ (3 сәгать).

Беренче занятие фугаслы һәм осколкалы авиабомбаларның макетларын (чертеж һәм рәсемнәрен) күрсәтеп һәм шулай ук, аларның җимерү эшләрен характерлаган чертеж һәм рәсемнәрне күрсәтеп, беседа алып бару методы белән үткәрелә. Яшерену урыны (убежище) булганда занятиене яшерену урынында үткәрергә һәм занятиенең ахырында шушы яшерену урынының төзелешен күрсәтергә һәм аңардан файдалану тәртипләрен аңлатырга кирәк.

Икенче занятие махсус сайланган площадкада (йорт эчендә, бакчада, бушлыкта, кырда) башыннан алып ахырына кадәр практик рәвештә уздырылырга тиеш. Кирәкле аңлатулар тирән чокырлар казу һәм аларны җиһазландыру процессында бирелә. Занятие өчен кирәкле барлык материаллар (казыклар, шнурлар һәм башкалар) һәм инструментлар (көрәкләр, балталар) занятиегә керешкәнче алдан хәзерләп куелырга тиеш. Занятие өчен кирәк булган материал һәм инструментларны, инструкторның шуннан элекке занятиедә кушуы буенча, өйрәнүчеләр үзләре белән алып киләләр. Күрсәтмә ярдәмлекләр (макетлар, чертежлар, плакатлар) булганда, алар практик эш процессында аңлату өчен файдаланыла. Кыш көнендә практик занятиеләр саклану чокырлары өчен урын сайлау, аны билгеләү һәм чокырларның юнәлешләрен билгеләү белән чикләнә, ә чокыр-

ларны казу һәм җиһазландыру эшләре белән өйрәнүчеләр электән (җәй көне) төзеп калдырылган чокырларда танышалар.

3 нче тема. Фугаслы һәм осколкалы бомбалардан зарарланучыларга беренче ярдәм

Занятиенең максаты. Зарарланганнарны коткару өчен, җимерелгән урыннарны актарып ачу эшләре белән таныштырырга; зарарланган кешеләр врачка күренүгә кадәр аларга ярдәм күрсәтергә өйрәтергә.

Теманың эчтәлеге. Ишелеп төшү куркынычы булган урыннарда терәкләр кую һәм киртәләү. Күмелеп калган яшеренү урыннарын (убежищеларны) һәм биналарны арчу һәм казуның гади ысуллары һәм кешеләрне аннан чыгаруның ысуллары һәм тәртипләре. Ишелгән урыннарны арчу буенча халык башкара торган эшләр. Зарарланганнарны җимерекләр астыннан коткарып алганда саклык белән эш итү чаралары. Кул астында булган средстволар ярдәме белән кан агуны туктату. Перевязка пакеты һәм аңардан файдалану. Тәннең һәрбер өлешендәге яраларны (берьяклы яки үтә чыккан яраларны) перевязка пакеты һәм бинт ярдәме белән бәйләү. Зарарланган кешеләрне кулга күтәреп яки кул астында булган әйберләр ярдәме белән күтәреп күчерү ысуллары. Яктырту газлары белән, углерод оксиды белән агуланган яки тәннең берәр җире өшегән хәлләрдә беренче ярдәм күрсәтү.

Занятие уздыруның методы. Тема ике занятиегә бүленә: беренче занятие — „Ишелгән урыннарны арчу эше“ (2 сәгать) һәм икенче занятие — „Дошман тарафыннан кулланылган фугаслы һәм осколкалы авиабомбалардан зарарланган кешеләргә врачка күренгәнче ярдәм күрсәтү“ (1 сәгать).

Беренче занятие, кирәкле объект булганда, практик занятие итеп үткәрелә, ә андый объект булмаганда, булуы мөмкин булган җимерелү һәм ишелү характеры турында һәм ишелгән урыннарны арчу эшен алып баруның тәртибе һәм аның техникасы турында сөйләп, занятие йорт янында алып барыла.

Икенче занятие бары тик практик занятие итеп кенә алып барыла: врачка кадәр ярдәм күрсәтүне практик рәвештә эшләп күрсәтү методы белән алып барыла; өйрәтелә торган кешеләр барысы да шуны үзләре эшләп күрсәтәләр. Моның өчен кирәк булган барлык материаллар

(перевязка пакетлары, бинтлар, кыстыргыч тугымнар (шиннар) һ. б.) өйрәнүчеләр тарафыннан тулысынча хәзерләп куелган булырга һәм алар бу материалларны үзләре белән занятиегә алып килергә тиешләр. Өйрәнүчеләргә бу турыда моннан элекке занятиедә әйтелә һәм киләчәктә үз-үзеңнән күнегү өчен бу материалларны булдырырга киңәш ителә. Ясалма рәвештә сулыш алдыру алымнарын өйрәтүне инструктор үзе практик рәвештә эшләп күрсәтә һәм өйрәнүчеләр шуны кабатлыйлар.

ИКЕНЧЕ НОРМА БУЕНЧА

4 нче тема. Яндыргыч средстволарның зарар итүе (1 сәгать)

Занятиенең максаты. Яндыргыч средстволарның зарар китерү эшенең характеры белән таныштырырга.

Теманың эчтәлеге. Яндыргыч авиабомбаларның һәм башка төрле яндыргыч средстволарның нәрсә өчен кулланылуы; аларның төзелешләре һәм җимерү эшләре турында белем. Дошман тарафыннан һәртөрле яндыргыч средстволар куллануның билгеләре. Төп яндыргыч матдәләрнең яну һәм зарар итү характеры.

Занятие уздыруның методы. Яндыргыч средстволарның макетларын (чертеж яки рәсемнәрен) күрсәтеп, һәм шулай ук аларның зарар итүләренең характерын аңлата торган чертеж һәм рәсемнәрне күрсәтеп беседа алып барыла. Яндыргыч матдәләр булганда аларның яну характеры күрсәтелергә тиеш.

5 нче тема. Үз өеңдә пожар чыгу куркынычын ничек итеп киметергә (4 сәгать)

Занятиенең максаты. Пожар чыгу куркынычын кимәтә торган чараларны үтәргә өйрәтү.

Теманың эчтәлеге. Пожар чыгу куркынычын кимәтә торган чаралар: чердакларны, коридорларны, баскычларны һәм баскыч асларын чистарту. Плиталарны, мичләрне, төтен юлларын, вентиляция каналларын, электр проводаларын һәм газ челтәрен төзек хәлдә тоту. Тиз кабынып китә торган матдәләрне дөрес саклау. Яндыргыч матдәләрне һәм пожарны сүндерү һәм аларга җәелергә ирек бирмәү өчен кирәк булган средстволар белән тәэмин ителү: ут сүндерә торган приборлар һәм инструментлар булдыру һәм аларны

өй эчендә тиешенчә урнаштыру; ком тутырылган ящиклар һәм капчыклар, су тутырылган һәм махсус эретмәләр (растворлар) салынган бочкалар булдыру. Куркыныч хәл (УП) игълан ителгәч ком запасын, су һәм махсус эретмәләр запасын арттыру. Пожар сүндергечләрне куркынычлырак урыннарга (чердакларга, коридорларга һ. б.) урнаштыру.

Занятие уздыруның методы. Инструктор занятие уздырырга тиеш булган бина (өй, мәктәп, учреждение һ. б.) белән алдан танышып куя һәм шушы мәгълүм бинага карата нинди чаралар күрергә кирәк икәнен хәл итә. Занятие үткәрү практик рәвештә алып барыла: бинаны бөтенләй карап чыгыла (чердакны, баскычларны, коридорларны һ. б.) һәм кайда нәрсә эшләргә кирәклеге, нинди средстволар хәзерләргә һәм аларны кайда һәм ни өчен урнаштырырга икәне күрсәтелә. Тиешле аңлатмалар бирү һәм күрсәтмәләр ясау бинаны карап йөргән вакытта үткәрелә.

6 нчы тема. Яндыргыч средстволарны һәм алардан килеп чыккан пожарларны сүндерү (4 сәгать)

Занятиенең максаты. Яндыргыч средстволарны һәм алардан килеп чыккан пожарларны сүндерергә өйрәтү.

Теманың эчтәлеге. Термит, фосфор, электрон һәм комбинацияләнгән бомбаларны һәм шулай ук башка төрле яндыргыч средстволарны сүндерү чаралары һәм ысуллары. Яндыргыч авиабомбаларын (ЗАБ) биналардан тышка чыгарып ташлау ысуллары. Бомбаларны суга һәм махсус эретмәләргә батыру һәм аларга су һәм махсус эретмәләр сибү. Яндыргыч бомба утының җәелүен туктату өчен ком куллану (ком мендәренә салу, ком сибү, ком постиле). Яндыргыч средстволар кулланудан туган пожарларны ут сүндерүчеләр һәм биналар эчендәге пожар сүндергеч краннар ярдәме белән сүндерү. Яна торган сыек нәрсәләрне сүндерү. Кеше өстендәге яна торган киемне сүндерү чаралары. Төтенләнгән һәм яна торган биналарда үз-үзеңне тоту кагыйдәсе. Пожар вакытында халыкны һәм әйберләрне күчерү. Пешүнең төрләре. Пешкән кешеләргә беренче ярдәм күрсәтү чаралары.

Занятие уздыруның методы. Тема икешәр сәгатьлек ике темага бүленә. Яндыргыч средстволарны алып ташлау, җәелергә ирек бирмәү һәм сүндерү өчен кирәк булган средстволар, һәм шулай ук пожар очагларын сүндерү средстволары алдан хәзерләнгән булырга тиешләр. Чын бомбага ошатып бомба ясау өчен болванкалар хәзер-

ләнеләһәм чын пожарга ошатып пожар күрсәтү өчен кирәкле средстволар хәзерләнелә. Кирәкле средстволарны һәм материалларны хәзерләү өчен инструктор өйрәнүчеләргә шуннан элекке занятиедә, аларның үзешчәнлекләрен киң рәвештә мобилизацияләп, тиешле задание биреп куярга тиеш. Бу бурычны үтәргә объектның ПВО начальниклары һәм йорт идарәләре дә тартыла. Занятиеләр махсус сайланган площадкада уздырылалар. Барлык сүндерү һәм ошатып ясау средстволары шул площадкада урнаштырыла. Занятие практик рәвештә алып барыла — инструктор бомбаны алып ташлау, җәелергә ирек бирмәү һәм алар белән эш итү алымнарын күрсәтә, һәм шуның белән бергә барлык өйрәнүчеләр сүндерү эшен эшләп карарга, инструктор күрсәткәннәрне кабатларга тиешләр. Аерым средстволарның (пожар краннарының, ут сүндергечнең) төзелеше, шушы средстволар белән эш итү процессында, эш техникасын белү өчен кирәк булган күләмдә аңлатыла. Яндыргыч средстволар белән көрәш алымнары кереш сүз белән обстановка аңлатып бирелгәннән соң эшләнә (мәсәлән, болай дигән обстановка бирелә: „Бередә бер ноктага юнәлдерелгән термит-электр бомбасы төште“. „Стабилизатор ягыннан якын киләм“. „Кыскыч белән эләктерәм“. „Алып ташлыйм“ һ. б.) һәм командирча итеп кыскача аңлатма һәм боерык бирелә.

ӨЧЕНЧЕ НОРМА БУЕНЧА

7 нче тема. Агулаучы матдәләр һәм аларны таный белү ысулы (2 сәгать)

Занятиенең максаты. Һава-химия һөҗүме вакытында кулланыла торган агулаучы матдәләрне (ОВ ны) таный белү ысулларын өйрәтү.

Теманың эчтәлеге. Агулаучы боевой матдәләр һәм аларның зарар итүләре турында кыскача мәгълүмат. Озак саклана торган (иприт һәм люизит) һәм озак сакланмый торган (фосген, дифосген, синиль кислотасы, адамсит, хлорацетофенон) агулаучы матдәләр (ОВ), аларның тышкы күренешләре һәм исләре. ОВ ның төрле комбинацияләрдә кулланылуы. Авиациянең озак саклана һәм озак сакланмый торган ОВ ны куллану ысуллары (химбомбалар, сиптергеч (выливные) һәм нечкә муенлы пыяла савыт (ампула) приборлары). Авиациянең ОВ ны куллану билгеләре. Һавада, урыннарда һәм әйберләрдә ОВ барлыкны таный белү ысуллары. ОВ ны тану

чаралары күргәндә саклык белән эш итү. Озак саклана торган ОВ белән агуланган урыннарны бүлеп куюю билгеләре.

Занятие уздыруның методы. Занятие беседа методы белән үткәреләә; беседаны ОВ ның үрнәкләрен күрсәтү (аларның төсләре һәм исләре белән таныштыру), химбомбаларның макетларын, аларның җимерү эшләренең характерын аңлаткан чертеж, рәсем яки фотоснимкаларны күрсәтү юлы белән алып барыла. Өйрәнүчеләр, занятиеләр үткәрү нәтиҗәсендә, ОВ куллануның барлык тышкы билгеләрен бик нык үзләштерергә тиешләр. Агуланган участокның ничек бүлеп куелуын урыннарда (йорт эчендә, өй янында яки урамда) практик рәвештә эшләп күрсәтергә кирәк.

8 нче тема. Агулаучы матдәләрдән саклану средстволары (5 сәгать)

Занятиенең максаты. Противогаз белән файдаланырга өйрәтү; ОВ белән агуланган районда торганда һәм агуланган участокны аша үткәндә саклану өчен кул астында булган средстволарны кулланырга өйрәтү; ашамлык продуктларны, су һәм өй кирәк-яракларын агуланудан сакларга өйрәтү.

Теманың эчтәлеге. Фильтрлый торган противогазлар БН, ДП. Аларның төзелешләре, аларның эш схемалары һәм аларның саклау хосусиятләре. Противогазның маскасын (шлемын) таманлаштыру. Куркыныч хәл игълан ителгәч һәм ВТ (һава тревогасы), ХТ (химия тревогасы) сигналы буенча противогазны җыйнау һәм аңардан файдалану кагыйдәләре. Противогазны салу һәм төреп кую. Противогазны тикшереп карау һәм аның бозыклыгын белү. Противогазның бозыклары булганда (маскасы ертылган, сырлы трубкасы, клапаннары бозылган, коробка һәм күзлекләре зарарланган вакытларында) противогаздан файдалану. Бозык противогазны төзек противогазга алмаштыру. Кыш көннәрендә противогаздан файдалану. Противогазны саклау. ОВ белән агуланган райондагы халыкның үз-үзен тоту кагыйдәләре. Озак саклана торган ОВ белән агуланган районнардан халыкны чыгару. Агуланган участоклар аша үтәр өчен кул астында булган средстволардан файдалану. Үтеп чыга торган урыннардан бару кагыйдәләре һәм үтеп барган вакытта саклык чараларын күрү. ОВ ның продуктларга, суга һәм өй кирәк-яракларына тәэсир итүе һәм

аларны агуланудан саклау чаралары. Һава-химия һөҗүменнән соң продуктлардан һәм судан файдалану кагыйдәсе.

Занятиене уздыруның методы. Тема өч занятиегә бүленә: беренче занятие — „Противогаздан файдалану“ (3 сәгать); икенче занятие — „Озак саклана торган ОВ белән агуланган участокны аша кичәр өчен кул астында булган средстволардан файдалану“ (1 сәгать); өченче занятие — „Ашамлык продуктларны, суны һәм өй кирәк-ярак әйберләрен саклау“ (1 сәгать). Беренче занятие башланганга кадәр противогазлар бирелә, аларны таманлау, җыйнау һәм сумкага салып кую үткәрелә.

Беренче занятиедә БН һәм ДП противогазларның төзелеше турында сөйләп аңлатыла (1 сәгать). Противогазларның төзелешләрен һәм эшләренең схемасын аңлату өчен, өйрәнүчеләргә бирелгән противогазның һәм противогазларның урталай ярылгандагы торышларын практик рәвештә күрсәтеп аңлатыла. Противогазлардан файдаланырга өйрәтү (2 сәгать) норма буенча таләп ителә торган барлык алымнарны инструкторның күрсәтүе белән алып барыла, һәм шуның белән бергә инструктор тарафыннан күрсәтелгән һәрбер алым, өйрәнүчеләр тарафыннан шунда ук кабатлана. Алымнарны үтәүне инструктор җентекле рәвештә күзәтергә, ә өйрәнүчеләр тарафыннан ясалган һәрбер ялгышны шунда ук төзәтергә тиеш. Өйрәнүчеләр шуннан соңгы барлык занятиеләргә противогаз алып килергә тиешләр һәм һәрбер занятиедә противогаздан файдалана белү тикшерелә; моның өчен, кинәт кенә „газ“ дип команда бирелә. Противогаз дөрес киелмәгән хәлләрдә тиешле аңлатма бирелгәннән соң, противогазның төзексезлеге турында кереш ясала һәм төзек булмаган противогаздан файдалана белү һәм аны төзек противогазга алыштыра белүне тикшереп карала. Тикшерү өчен һәрбер занятиедә 10 минут вакыт бирелә. Аннары өйрәнүчеләр „газ“ дигән команда буенча противогазларын киями һәм противогаздан утыралар: беренче занятиедә 15 минут, ә аннан соңгыларында арттыра барыла — 25, 35, 45 һәм 60 минутка кадәр җиткерелә. Шуннан тыш тагын инструктор өйрәнүчеләргә противогаздан файдалану һәм противогаз киеп тору алымнары буенча үзлекләреннән күнегү ясарга күрсәтмәләр бирә.

Икенче занятие практик рәвештә үткәрелә, шуның белән бергә өйрәнүчеләргә, үткән занятиедә, бу занятиегә үзләре белән төрле ярдәмче средстволар (такталар, чыпта, галошлар, перчаткалар, плащлар, яулыклар, шарфлар һ. б.) алып килергә кушыла. Йорт эчендә шартлы рәвештә агуланган участоктан аша үтү юлы билгеләнелә. Агуланган

районда торганда һәм агуланган участоктан аша үткәндә үз-үзеңне ничек тоту турында аңлатканнан соң, инструктор өйрәнүчеләрне агуланган участок аша үтәргә фактик рәвештә хәзерли. Ул аларны бинадан чыгара һәм шартлы рәвештә агуланган участок аша үткәрә, агуланган участокны чыгып җиткәч, ярдәмче средстволарны (галош, бияләй һ.б.) салу кагыйдәсен һәм шуннан соң үз-үзләрен ничек тотарга икәнен аңлата.

Өченче занятиедә су савытларын томалау (герметизация), продуктларны һәм өй кирәк-яракларын яшерүнең ничек эшләнүен күрсәтеп беседа үткәрелә. Күрсәтү өчен кирәк булган предметларны һәм материалларны занятиегә инструктор һәм шулай ук өйрәнүчеләр үзләре алып киләләр.

9 нчы тема. Агулаучы матдәләр белән зарарлануның билгеләре һәм зарарланучыга врачка кадәр ярдәм күрсәтү (2 сәгать)

Занятиенең максаты. Химиягә каршы пакеттан файдаланырга һәм ОВ дан зарарланган хәлләрдә врачка кадәр ярдәм күрсәтергә өйрәтү.

Теманың эчтәлеге. Тәннең тиресенә зарар итә торган ОВ дан (иприттан һәм люизиттан) зарарлануның билгеләре. Химия һөҗүменә каршы пакетның төзелеше һәм аның эчендәге әйберләр. Зарарланган урыннарны химия һөҗүменә каршы пакет һәм кул астында булган әйберләр ярдәме белән эшкәртү техникасы. Юу пунктын үтү тәртибе. Тончыктыргыч, гомумән агулы һәм башка ОВ белән агулану билгеләре һәм шушы ОВ лар белән агуланган хәлләрдә врачка кадәр ярдәм күрсәтү. Зарарланган кешегә противогаз кигезү.

Занятие уздыруның методы. Занятие беседа юлы белән алып барыла; төрле ОВ дан зарарлануның билгеләре турында кыскача аңлату ясала, һәм химия һөҗүменә каршы пакеттан ничек итеп файдаланырга икәнен һәм зарарланган кешегә ничек итеп противогаз кигезергә икәне күрсәтелә. Озак саклана торган ОВ белән агуланган урыннарны зарарсызландыру алымнарын һәм зарарланган кешегә противогаз кигезүне барлык өйрәнүчеләр кабатлыйлар. Занятиене үткәрү өчен, химия һөҗүменә каршы пакеттан башка тагын марля тампоннары һәм эреткечләр (боларны инструкторның күрсәтүе буенча занятиегә өйрәнүчеләр алып киләләр), һәм шулай ук иприттан зарарлануны күрсәтә торган муляжлар, рисунк һәм плакатлар булдырырга кирәк.

ДҮРТЕНЧЕ НОРМА

10 нчы тема. Торак йортта ПВО оештыру (2 сәгать)

Занятиенең максаты. Торак йортта (предприятиедә, учреждениедә, уку йортында) ПВО оештыру белән таныштыру һәм яктылыкны яшерергә өйрәтү.

Теманың эчтәлеге. Торак йортта (предприятиедә, учреждениедә, уку йортында) ПВО оештыру. Иортта (предприятиедә, уку йортында, учреждениедә) ПВО хезмәтендәге кешеләр. Үз-үзеңне саклау группалары (ПВО командалары) билгеләү һәм оештыру. Тыныч вакытта һәм куркынычлы хәл башлангач йортларны ПВО га хәзерләү эшләре. Йортларда яктылыкны яшерүдә халыкның бурычлары: квартирадагы, баскычтагы һәм хезмәт биналарындагы тәрәзә һәм ишекләрдән күренүе мөмкин булган яктылыкны ничек яшерү-томалау ысуллары.

Занятие уздыруның методы. Торак йортта (предприятие һ. б.) ПВО оештыру белән таныштыру — өйрәнүчеләрнең шушы группасы хәзерләнә торган объектта ПВО планының конкрет мисалы өстендә алып барыла; объектның ПВО эшендәге кешеләрен, үз-үзеңне саклау группасының (ПВО командасының) составы күрсәтелә һәм йортны (учреждениене, мәктәпне) ПВО га хәзерләүдәге чаралар күрсәтелә. Өйрәнүчеләр инструктор белән берлектә йортны (мәктәпне, учреждениене һ. б.) карап йөреп чыгалар, һәм карап йөргәндә инструктор шушы йортның (мәктәпнең, учреждениенең һ. б.) ПВО буенча булган барлык элементларын аңлата. Инструктор яктылыкны яшерүне (тәрәзә һәм ишекләрне томалауны) практик рәвештә эшләп күрсәтә. Моның өчен кирәкле материаллар (яктылыкны каплый торган кәгазьләр, газета кәгазьләреннән, әйбер төрә торган кәгазьләрдән яки обой кәгазьләреннән ябыштырып ясалган шторлар, одеяллар һәм башкалар) занятиегә алдан хәзерләп куелалар. Занятие вакытында инструктор өйрәнүчеләргә үзләренең өйләрендә яктылыкны томалауны эшләп карарга куша. Шуннан соң (занятие вакытыннан тыш) кич белән, өйрәнүчеләрнең бөтен группасы, аларның һәркайсының тора торган урыннарын йөреп чыга һәм аларның квартираларында яктылыкны томалауның сыйфатын тикшерә.

11 нче тема. ПВО шартларында халыкның үз-үзен тоту бурычлары һәм аның кагыйдәләре (2 сәгать)

Занятиенең максаты. ПВО буенча халыкның үз-үзен тоту бурычларын һәм аның кагыйдәләрен өйрәнү.

Теманың эчтәлеге. „Куркыныч хәл“; ул кем тарафыннан кайчан һәм ничек игълан ителә. Куркыныч хәл (УП) игълан ителгән чакларда халыкның үзенең өендә һәм өеннән чыккан вакытларында күрә торган чаралары. „Һава тревогасы“ сигналы; ул сигнал шәһәрдә һәм йортта кем тарафыннан һәм нинди средстволар ярдәме белән бирелә; аның әһәмияте. Һава тревогасы буенча халыкның өйдә, урамда, эштә һәм җәмәгать урыннарында үз-үзен тоту бурычлары һәм аның кагыйдәләре. „Химия тревогасы“ сигналы; ул нинди средстволар ярдәме белән бирелә; аның әһәмияте. ХТ сигналы буенча өйдә, урамда, эштә һәм җәмәгать урыннарында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре. Пожар вакытында халыкның өйдә, җәмәгать урыннарында һәм эштә үз-үзен тоту бурычлары һәм аның кагыйдәләре. Шәһәрдә, өйдә, предприятиедә, учреждениедә, уку йортында „һава тревогасы отбое“ сигналын игълан итү тәртибе һәм аның средствосы. „Отбой“ сигналының әһәмияте һәм ул сигнал буенча үз-үзеңне ничек тоту кагыйдәсе.

Занятие уздыруның методы. Плакатлар күрсәтеп беседа ясау.

ПВО буенча үз-үзеңне тоту кагыйдәсен өйрәнү урыннардагы хезмәт иясе депутатлары советларының мәҗбүри карарлары нигезендә уздырыла.

ОРГАНИЗАЦИОН КҮРСӘТМӘЛӘР

Занятие уздыру

Халыкны ПВХО ның 1 нче баскыч нормаларын тапшыруга хәзерләү кешенең эшли торган (укый торган, тора торган) урынында Осоавиахимның завод, фабрика, учреждение, мәктәп, йорт һ. б. янындагы башлангыч оешмалары тарафыннан уздырыла.

ПВХО ның 1 нче баскыч нормалары программасы буенча өйрәнүне 16 яшьтән үткән гражданнар үтәләр. 10 нан 15 яшькә кадәр булган балалар ПВХО нормаларына хәзерләнү һәм аны тапшыруны аерым программа буенча үтәләр.

Норма тапшыруга әзерләнү өчен Осоавиахимның башлангыч оешмалары тарафыннан цехларда (отделларда, классларда) 20—25 кешедән торган составта ПВХО түгәрәкләре төзелә. Түгәрәктә өйрәнүчеләрнең берсе түгәрәкнең старостасы итеп билгеләнә.

Түгәрәккә кергән кешеләрне норма тапшыруга хәзерләү эшен Осоавиахимның башлангыч оешмасы тарафыннан бил-

геләнгән ПВХО инструкторы алып бара. ПВХО инструкторы итеп оешманың активларыннан, Осоавиахимның район советы тарафыннан шул эшкә яраклы табылган, сыналган кеше билгеләнә.

Осоавиахимның район советларының һәм башлангыч оешмаларынын командир-инструкторлары һәм ПВХО секцияләре инструкторларны түгәрәкне хәзерләүне оештыру буенча көндәлек консультация һәм методик җитәкчелек белән тәэмин итеп торырга тиешләр.

Халыкны ПВХО нормаларын тапшыруга хәзерләү эшләренең барсын да инструктор җәмәгать эшләре тәртибендә (түләүсез) башкара, һәм занятиеләрне үзенең дә һәм өйрәнүчеләрнең дә эш вакытыннан тыш, ягъни, эштән соң яки эшкә кадәр уздыра.

Түгәрәкнең программа буенча үткәрелгән һәрбер занятиесе һәм занятиедә булучыларның саны ПВХО занятиеләренең махсус журналына языла.

Һәрбер занятие барыннан элек практик занятие булырга, өйрәнүчеләргә ПВХО буенча билгеле бер күнегү бирерлек булырга тиеш. Моңа ирешү өчен инструктор (Осоавиахим советы һәм аның ПВХО секциясе аркылы, һәм шулай ук өйрәнүчеләрнең үз инициативасы белән) һәрбер занятиене тема буенча кирәк булган уку һәм күргәзмә материаллар, приборлар, ярдәмче һәм имитация (ошатып ясалган) средстволар белән тәэмин итәргә тиеш.

Занятиеләр уздыру белән бергә, өйрәнүчеләргә ПВХО буенча тиешле әдәбият укуны тәкъдим итәргә („ПВХО га хәзер бул“, брошюрасы, Воениздат, 1940 нчы (яки 1941 нче ел) басмасы. „Һава дошманнарына каршы оборонага өйрән“ ВЛКСМ ҮК басмасы, 1941 нче ел. Һәм башка брошюралар).

Моннан тыш тагын, массовый эш тәртибендә ПВХО буенча массовый лекцияләр оештырырга, ПВХО буенча кинофильмнар карарга кирәк һәм башкалар.

Заводта радиотрансляция узелы булганда Осоавиахим советы тарафыннан, „ПВХО га хәзер“ нормаларының беренче баскыч нормаларына ярашлы итеп перерыв вакытларында ПВХО буенча радио беседалар тапшыру оештырылырга тиеш.

УЧЕБНЫЙ КИНОФИЛЬМНАРНЫ ФАЙДАЛАНУ

Өйрәнүчеләрнең материалны үзләштерүләрен җиңеләйтү өчен һәм аларга ПВО вакытында обстановка характерын, халыкның үз-үзен тотуын һәм хәрәкәтен, һәм шулай

ук саклану техникасын җанлы, динамик рәвештә күрсәтеп аңлату өчен, түгәрәк занятиеләре белән бергә ПВХО буенча кинофильмнар да күрсәтергә кирәк.

Кинофильмнарны занятиеләрдән соң түгел, бәлки һәрбер норманы практик эшләүгә кадәр, аның кереш өлеше итеп күрсәтергә кирәк.

Фильмнар күрсәтү занятиенең план сәгатьләреннән тыш эшләнә. Ләкин фильмны күрсәтү инструкторның кереш сүзе белән башланырга, һәм картинаны карау дәвам иткәндә инструктор тарафыннан аңлату биреп торылырга тиеш.

Фильмны, урын сыйдыруына карап, бер үк вакытта берничә группага күрсәтелә.

Кинофильмнар түбәндәге тәртиптә күрсәтелергә тиеш.

Кереш беседадан соң:

„Һава налеты".

Беренче норма алдыннан:

„ОВ дан коллектив рәвештә саклану",
„Тар чокырлар (щели)",
„Ясалма сулыш" (өч минутлык фильм).

Икенче норма алдыннан:

„Яндыргыч бомбаларның төзелешләре һәм аларны сүндерү",
„Ут сүндергечләрдән файдалана бел" (өч минутлык фильм).

Өченче норма алдыннан:

„Агулаучы боевой матдәләр",
„Химия һөҗүменнән индивидуаль рәвештә саклану",
„Азыкларны ОВ дан саклый бел".

Дүртенче норма алдыннан:

„Торак йортта ПВО" (мәктәп өчен „мәктәптә ПВО"),
„Һава тревогасы" сигналы",
„Химия тревогасы" сигналы",
„Торак йортларның яктысын яшерү",
„Безнең өй яктылыкны яшерүгә хәзер" (өч минутлык фильм).

Нормалар кабул итү

Түгәрәктә хәзерләү тәмам булганнан соң яки нормалар тапшыруга индивидуаль рәвештә хәзерләнүләрдән соң Осоавиахим советы нормалар кабул итү көнен билгели.

Нормаларны кабул итүнең урыны, көне һәм сәгате цехларда, группаларда, торак йортларда һ. б. игълан ителә, анда нормалар тапшыручылар һәм шулай ук нормалар тапшырырга хәзерләнүчеләр дә чакырыла.

Программаны кайда үткән булуына карамастан, һәрбер граждан нормалар тапшыра ала.

Нормалар кабул итүне бары тик Осоавиахим советы тарафыннан расланган комиссияләр генә башкара алалар. Бу комиссияләр өч кешедән ким булмаган составта Осоавиахим советы һәм урыннардагы ПВО органнары вәкилләреннән төзелә (ПВО вәкиле комиссиягә предприятие, учреждение, йорт ПВО начальнигының билгеләве буенча керә).

Нормалар кабул итү буенча булган комиссия составына ПВХО ның 2 нче баскыч инструктор-значкист күләмендә хәзерлеге булган кешеләр генә билгеләнә ала.

Башлангыч зур Осоавиахим оешмаларында норма тапшырулар массовый төстә булганда берничә комиссия төзелә. Ул комиссияләр аерым цехларда, отделларда һ. б. нормалар кабул итүне алып баралар.

Шул группаны хәзерләү эшен алып барган инструктор шушы үзе хәзерләгән группадан нормалар кабул итү комиссиясенә билгеләнә алмый.

Нормалар кабул иткәндә түбәндәгеләр тикшерелергә тиеш: 1) Саклану средстволарыннан файдалана белү һәм 2) „ПВХО га хәзер" нормаларының беренче баскычында билгеләнгәннәрне белү.

Саклану средстволарыннан файдалана белү бары тик практик рәвештә генә тикшерелергә тиеш; нормалар күләмендә белемнәре барлыгы нормалар тапшыручының тиешле күнегүләрне үзләштерүен практик рәвештә тикшереп карау процессында тикшерелә.

Практик күнегүләрен тикшереп карамыйча, беседа рәвешендә генә нормалар кабул итү кискен рәвештә тыела.

Нормалар кабул итү, шушы таләпләргә туры китереп, һәрбер норма буенча тиешле рәвештә хәзерләнгән урыннарда: тиешле әйберләр белән тәэмин ителгән площадкаларда, яшерену урыннарында (убежищеларда) саклану өчен казылган тар чокырларда, өй чердагында һ. б. уздырылырга тиеш.

Нормалар тапшыру урыннарында обстановка, һәм шулай ук күрсәтмә ярдәмлекләр, әйберләр, материаллар, макетлар, чертежлар һ. б. занятие уздыруга хәзерләнгән вакыттагы кебек үк хәзерләнергә тиеш.

Норма тапшыручыларның хәрәкәтләрен һәм практик күнегүләрен, таләп ителә торган алымнарны һәм хәрәкәтләрне үтәр өчен кирәкле обстановканы билгеләүче керешләр ясау фонасында тикшерергә кирәк.

Белемнәрен тикшергәндә дә элек мәгълүм обстановка (кереш обстановка) бирергә кирәк, ә аннары җавап бирүне, мәсьәләне хәл итүне, яки хәрәкәт итүне таләп итәргә кирәк.

Нормалар тапшыручы һәрбер кеше нормаларны үзе теләгән тәртиптә тапшырырга хаклы: мәсәлән, башта 4 нче норманы тапшыра, аннары 2 нчене һ. б.

Нормалар кабул итүче комиссия членнары норма тапшыручыларга карата бик таләп итүчән булырга тиешләр, бигрәк тә практик рәвештә үти белүне, нормаларда ПВХО таләп иткәннәрне практик рәвештә үти белүне нык сорарга кирәк, нормада таләп ителгәннәрдән аз гына да чигенү булмаска тиеш. Сорауны йомшартучы комиссия членнары, һава һөҗүменә каршы оборонага илнең хәзерләнүен какшатучы сыйфатында, комиссиядән чыгарыла, нормалар кабул итү хокукыннан мәхрум ителә.

Сынау нәтиҗәләрен комиссия занятиеләр журналы актына кертә, анда һәрбер норманың тапшырылуы аерым рәвештә языла. Акт башлангыч оешмада кала, Осоавиахимның район советына норма тапшырган кешеләрнең гомуми саны турында белдерелә.

„ПВХО ГА ХӘЗЕР“ НОРМАЛАРЫНЫҢ 1 НЧЕ БАСКЫЧЫН ТАПШЫРУЧЫЛАРНЫҢ УЧЕТЫ

1. „ПВХО га хәзер“ нормаларының 1 нче баскычын тапшырганнарның барлык учеты Осоавиахимның башлангыч оешмаларында туплана.

2. ПВХО нормаларын тапшырганнарның учетын оештыруда персональ рәвештә җаваплылыкны, советның раславы буенча, Осоавиахимның башлангыч оешмасы советы членнарыннан берсе яки ПВХО секциясенең председателе алып бара.

3. Учет „ПВХО га хәзер“ нормаларының 1 нче баскычын тапшыру турында занятиеләр журналында язылган актлар буенча алып барыла (чөнки ул журналны нормалар кабул итү комиссиясе үзенең эшен тәмам иткәч советка тапшыра).

4. Комиссия актлары нигезендә башлангыч оешма советы норма тапшырганнарның барсына да удостоверение бирә. Норма тапшырганлыклары турында Осоавиахимның членлыгы турындагы учет карточкаларына язып куела.

5. Осоавиахимның башлангыч оешмасы советы ПВХО нормаларын тапшырганнарның (акт буенча) агымдагы учетыннан башка тагын 2 еллык вакыт эчендәге, ягъни тапшырылган нормаларның эшкә яраклы булып саналу срогы эчендә норма тапшырганнарның барсын да учетка алырга тиеш. Моның өчен һәрбер цех оешмаларында (яки цех оешмасына тигез булган башка оешмаларда), Осоавиахим членнарын учетка алган кебек, барлык эшләүчеләрнең ПВХО нормаларын тапшыручылары учетка алына.

Оешма эчендә норма тапшыручылар турында мәгълүматлар исемлеккә акт нигезендә язылалар. Башка оешмалардан күчеп килүчеләр үзләре белән китергән документлары нигезендә учетка алыналар.

„ПВХО га хәзер“ нормаларының 1 нче баскычын тапшырган кешеләрдән берәрсе оешмадан киткән хәлләрдә, аның оешмадан китүе турында актка һәм учет исемлегенә язып куела.

СССР Осоавиахимы Үзәк Советының ПВХО идарәсе начальнигы полковник: *КОТЛИНСКИЙ.*

ЭЧТӘЛЕГЕ

Бит

„ПВХО га хәзер“ нормаларының 1 нче баскычы 3
Уку вакытының хисабы 5
„ПВХО га хәзер“ нормаларының беренче баскычы буенча занятиеләр программасы 6
Организацион күрсәтмәләр 16

НОРМЫ „ГОТОВ К ПВХО“
I-Й СТУПЕНИ

(На татарском языке)

Җаваплы редактор И. Исхаков

Басарга кул куелды 18/VII-41 ел. Тираж 10070. Басма табак $1^1/_2$. Табакта 44000 хәреф. Авт. 1,0 табак. ПФ 1542. Заказ № 195. Бәясе 20 тиен.
Басылды Камиль Якуб исемендәге китап фабрикасында.
Казан, Бауман урамы 19. 1941 ел.

Бәясе 20 тиен